Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы

# Б О Е Р Ы К

2014 елның 24 феврале Казан ш. № 33/2-пр

2014 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Нәселле терлекчелеккә ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында” 2012 елның 4 декабрендәге 1257 номерлы, “Үсемлекчелекнең аерым тармакларына ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 12 декабрендәге 1295 номерлы, “Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең сатылган товар сөтнең 1 литрына (килограммына) чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 22 декабрендәге 1370 номерлы, “Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 22 декабрендәге 1371 номерлы, “Үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 27 декабрендәге 1431 номерлы, “Россия кредит оешмаларында алынган кредитлар буенча һәм авыл хуҗалыгына кагылышлы кредит бирә торган кулланучылар кооперативларында алынган заемнар буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 28 декабрендәге 1460 номерлы карарлары нигезендә

б о е р ы к б и р ә м:

1. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирүнең кушымта итеп бирелгән түбәндәге тәртипләрен расларга:

1.1. 2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (1 нче кушымта);

1.2. 2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең элиталы орлык сатып алу чыгымнарының бер олешен каплау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (2 нче кушымта);

1.3. 2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләрен, интенсив типтагы бакчаларны утырту һәм карау чыгымнарының бер олешен каплау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (3 нче кушымта);

1.4. 2014 елда файдаланылмый торган иске бакчаларны төпләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны рекультивацияләү чыгымнарының бер олешен каплау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (4 нче кушымта);

1.5. 2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөт чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (5 нче кушымта);

1.6. 2014 елда нәселле терлекчелеккә ярдәм итү өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (6 нчы кушымта);

1.7. 2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (7 нче кушымта);

1.8. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына 2 елдан алып 15 елга кадәрге срокка алынган инвестиция кредитлары буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен 2014 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (8 нче кушымта);

1.9. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына 8 елга кадәр срокка алынган кредитлары һәм заемнары буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен 2014 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (9 нчы кушымта);

1.10. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш), оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына 2010-2014 елларда 1 елга кадәрге срокка Россия кредит оешмаларында алынган кредитлар буенча һәм авыл хуҗалыгына кагылышлы кредит бирә торган кулланучылар кооперативларында алынган заемнар буенча процентлар түләү чыгымнарының

бер өлешен каплау очен 2014 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (10 нчы кушымта).

2. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү өчен документларның кушымта итеп бирелгән формаларын расларга:

2.1. 2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү буенча исәп-хисап белешмәләре формасы (11 нче кушымта);

2.2. 2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү буенча җыелма исәп-хисап белешмәләре формасы (12 нче кушымта);

2.3. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә авыл хуҗалыгы культураларының элиталы орлыклар сатып алуга субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләре формасы (13 нче кушымта);

2.4. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә авыл хуҗалыгы культураларының күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләрен утырту һәм карауга субсидияләр бирү очен исәп-хисап белешмәләре формасы (14 нче кушымта);

2.5. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә файдаланылмый торган иске бакчаларны топләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны рекультиваңияләүгә субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләре формасы (15 нче кушымта);

2.6. Авыл хуҗалыгы товарын җитештерүченең физик авырлыгындагы товар сотне сату һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрү фактын раслый торган документларының реестры формасы (16 нчы кушымта);

2.7. Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча физик авырлыгындагы товар сотне сату һәм (яки) үз эшкәртүенә җибәрү буенча җыелма реестрның формасы (17 нче кушымта);

2.8. Татарстан Республикасы буенча физик авырлыгындагы товар сотне сату һәм (яки) үз эшкәртүенә җибәрү буенча җыелма реестрның формасы (18 нче кушымта);

2.9. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең 2014 ел кварталында сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү очен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөт чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләре формасы (19 нчы кушымта);

2.10. Татарстан Республикасы муниңипаль районының авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләренә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең 2014 ел кварталында сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөт чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләре формасы (20 нче кушымта);

2.11. Татарстан Республикасы муниңипаль районының авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчесенә 2014 елда сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөт чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен сыерларның баш саны, сөт

җитештерү, сөт продуктивлыгы һәм бозаулар туу буенча кварталлык күрсәткечләренең формасы (21 нче кушымта);

2.12. Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә 2014 ел кварталында сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөт чыгымнарының бер өлешен каплау очен федераль бюджеттан субсидияләр бирү очен сыерларның баш саны, сөт җитештерү, сөт продуктивлыгы һәм бозаулар туу буенча җыелма кварталлык күрсәткечләренең формасы (22 нче кушымта);

2.13. Татарстан Республикасы муниципаль районының авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчесенә 2014 елда сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөт чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен сыерларның баш саны, сөт җитештерү, сөт продуктивлыгы һәм бозаулар туу буенча еллык күрсәткечләренең формасы (23 нче кушымта);

2.14. Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең 2014 елда сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөт чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен сыерларның баш саны, сөт җитештерү, сөт продуктивлыгы һәм бозаулар туу буенча җыелма еллык күрсәткечләренең формасы (24 нче кушымта);

2.15. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче тарафыннан узган елда сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән терлекчелек продукцияләренең сыйфаты турында белешмәләрнең формасы (25 нче кушымта);

2.16. Сөт җитештерү, сыерларның сөт бирүе һәм 100 баш сыерга туры килә торган бозаулар саны турында мәгълүматның формасы (26 нчы кушымта);

2.17. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә нәселле терлекчелеккә (авыл хуҗалыгы терлегенең нәселле ана башларын асрауга, сөт һәм ит нәсел үгезләрен асрауга) ярдәм итүгә субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләре формасы (27 нче кушымта);

2.18. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә нәселле терлекчелеккә (нәсел үгезләрен, нәселле яшь мөгезле эре терлекне, нәсел үгезләре орлыкларын, нәселле яшь мөгезле эре терлек эмбрионнарын сатып алуга) ярдәм итүгә субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләре формасы (28 нче кушымта);

2.19. Финанслар белән тәэмин итү чыганакларының берсе авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы иминләштерүе (2013 елда чәчелгән көзге авыл хуҗалыгы культураларының уңышын иминләштерү) шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләүгә чыгымнарының бер өлешен каплау белән бәйле Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидия бирү булган субсидияләрнең күләме турындагы белешмәнең формасы (29 нчы кушымта);

2.20. Финанслар белән тәэмин итү чыганакларының берсе авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы

иминләштерүе (берьеллык культураларның 2014 ел уңышын иминләштерү) шартнамәләре буенча нминият премияләрен түләүгә чыгымнарының бер өлешен каплау белән бәйле Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидия бирү булган субсидияләрнең күләме турындагы белешмәнең формасы (30 нчы кушымта);

2.21. Финанслар белән тәэмин итү чыганакларының берсе авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы иминләштерүе (2014 елда чәчелгән көзге авыл хуҗалыгы культураларының уңышын иминләштерү) шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләүгә чыгымнарының бер өлешен каплау белән бәйле Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидия бирү булган субсидияләрнең күләме турындагы белешмәнең формасы (31 нче кушымта);

2.22. Финанслар белән тәэмин итү чыганакларының берсе авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы иминләштерүе (күпьеллык үсемлекләрнең уңышын иминләштерү) шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләүгә чыгымнарының бер өлешен каплау белән бәйле Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидия бирү булган субсидияләрнең күләме турындагы белешмәнең формасы (32 нче кушымта);

2.23. Финанслар белән тәэмин итү чыганакларының берсе авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы иминләштерүе (күпьеллык үсемлекләрнең үсентеләрен иминләштерү) шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләүгә чыгымнарының бер өлешен каплау белән бәйле Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидия бирү булган субсидияләрнең күләме турындагы белешмәнең формасы (33 нче кушымта);

2.24. Финанслар белән тәэмин итү чыганакларының берсе авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең терлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы иминләштерүе (авыл хуҗалыгы хайваннарын иминләштерү) шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләүгә чыгымнарының бер өлешен каплау белән бәйле Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидия бирү булган субсидияләрнең күләме турындагы белешмәнең формасы (34 нче кушымта);

2.25. Иминият оешмасының исәп-хисап счетына субсидияләр күчерү турында гариза формасы (35 нче кушымта);

2.26. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә заемчы алган кредит (заем) буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр күләмен исәпләү формасы (36 нчы кушымта);

2.27. 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, заемчы (авылда хуҗалык алып баруның кече формалары) алган кредит (заем) буенча процентлар

түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр күләмен исәпләү формасы (37 нче кушымта);

2.28. 2013 елның 1 гыйнварыннан соң, шул көнне дә кертеп, заемчы (авылда хуҗалык алып баруның кече формалары) алган кредит (заем) буенча проценттлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр күләмен исәпләү формасы (38 нче кушымта);

2.29. Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча авылда хуҗалык алып баруның кече формалары тарафыннан алынган кредитлар һәм заемнар буенча федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен исәп-хисаплар формасы (39 нчы кушымта);

2.30. Субсидияләр бирү турында гариза формасы (40 нчы кушымта);

2.31. Кредитны (заемны) түләп бетерү һәм кредит шартнамәсе буенча процентлар түләү графигы формасы (41 нче кушымта);

2.32. Агымдагы финанс елына субсидияләрнең күләмен план буенча исәпләү формасы (42 нче кушымта);

2.33. Кредит акчаларын үзләштерү турында белешмә формасы (43 нче кушымта);

2.34. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына 8 елга кадәр срокка алынган кредитлары һәм заемнары буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү турында гаризаның түләү реквизитлары һәм фочта адресы күрсәтелгән формасы (44 нче кушымта);

2.35. Татарстан Республикасы муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тарафыннан алынган кредитның максатчан кулланылышын тикшерү турында акт формасы (45 нче кушымта).

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

дәүләт ярдәмен алучылар квартал беткәннән соң 20 көн эчендә, ел беткәннән соң 60 көн эчендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы) Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарәләр) авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) финанс-икътисадый торышы турында хисап тапшыралар;

Идарәләр ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгына авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең финанс-икътисадый торышы турында җыелма хисап тапшыралар;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр финанс-икътисадый торышлары турында хисапны үз вакытында тапшырмасалар, Министрлык дәүләт ярдәме чараларын күрсәтүне туктатып торырга хокуклы.

4. Тапшырыла торган документларның дөреслеге, бюджет акчаларының максатчан кулланылуы өчен җаваплылыкны субсидияләрне алучы оешмаларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына, Идарәләр башлыкларына һәм идарәләрнең финанс-икътисадый бүлекләре башлыкларына йөкләргә.

5. ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының финанс бүлеге башлыгы М.А. Мәхмүтовка:

5.1. Әлеге боерыкның 1, 2 пунктларында каралган тәртипләр нигезендә ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының финанс бүлеге белгечләре тарафыннан федераль бюджеттан субсидияләр алу өчен документлар кабул итүне тәэмин итәргә.

5.2. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр финанс-икътисадый торышлары турында хисапны үз вакытында тапшырмасалар, дәүләт ярдәме чараларын күрсәтүне туктатып торырга.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасарлары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

________ елның ___номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
1 нче кушымта

2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип милекчелек формаларына бәйсез рәвештә үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алын баручы гражданнардан тыш) үсемлекчелек өлкәсендә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү өчен 2014 елда федераль бюджеттан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидияләр, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр).

2. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрен сайлап алу критерийлары:

а) үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату;

б) милек яки аренда шартларында авыл хуҗалыгы культураларын чәчү мәйданнарының булуы.

3. Субсидияләр бирү максатлары:

а) авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең 1 гектар чәчү мәйданына исәпләгәндә агротехник эшләр комплексын уздыру чыгымнарының бер өлешен каплау;

б) авыл хуҗалыгы производствосының экологик куркынычсызлыгы дәрәҗәсен арттыру;

в) туфракның уңдырышлылыгын һәм туфрак сыйфатын арттыру.

4. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өчен субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$V = П \times (135{,}6 + (2{,}36 \times У) + (45{,}17 \times И_{пп\ мр}))$

Монда:

V – күчерелергә тиешле субсидияләрнең күләме, сум;

П – гектарда исәпләгәндә, планлаштырылган чәчү мәйданы, алга таба ул № 4-СХ яки № 1-фермер формалары буенча “2014 ел уңышын алу өчен чәчү йомгаклары турында белешмәләр” статистик хисабында (алга таба – чәчү турында статистик хисап) расланачак ;

135,6 – бер гектар чәчү мәйданының минималь ставкасы, сум;

2,36 – ашлык берәмлекләрен җитештерүнең 1 центнерына ставка, сум;

У – авыл хуҗалыгы культураларының уртача уңдырышлылыгы, ул Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Авыл хуҗалыгы культураларын ашлык берәмлекләренә күчерү коэффициентларын раслау турында” 2013 елның 11 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгы нигезендә чәчү буенча статистик хисапларга һәм № 29-СХ формасы яки “Авыл хуҗалыгы культураларының уңышын җыю турында белешмәләр” № 1-фермерга нигезләнеп уртача соңгы 5

елда чәчүлекләрнең 1 гектарыннан алынган ашлык берәмлекләре центнерларында күрсәтелә. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүченең биш еллык тарихы булмаса, аның фактик эшчәнлек чоры, ә яңа төзелгән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өчен – соңгы 5 елда муниципаль район буенча уртача уңдырышлылык исәпкә алына.;

45,17 – чәчүлекнең бер гектарына җирләрнең уңрырышлылыгы буенча уртача ставка, сум;

$И_{пп.мр}$ – Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча туфрак уңдырышлылыгының уртача алынган индексы, ул әлеге тәртипкә кушымта нигезендә “Татарский” агрохимия хезмәте үзәге” Федераль дәүләт бюджет учреждениесе һәм “Әлмәт” агрохимия станциясе” Федераль дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан тапшырылган мәгълүматларга нигезләнеп Рф Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Россия Федерациясе субъектында туфрак уңдырышлылыгы күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында” 2013 елның 11 гыйнварындагы 5 номерлы боерыгы белән расланган методика нигезендә билгеләнә.

5. Субсидия алу очен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Татарстан Республикасы муниципаль районнарында ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гариза;

соңгы 5 ел өчен субсидия алучылар тарафыннан таныкланган № 4-СХ формасын яки № 1-фермер “Уңыш җыю өчен чәчү йомгаклары турында белешмәләр”не (алга таба – чәчү турында статистик хисап), № 29-СХ формасын яки № 2-фермер “Авыл хуҗалыгы культураларының уңышын җыю турында белешмәләр”ен (алга таба – уңыш җыю турында статистик хисап);

әлеге боерыкныҗ 11 кушымтасында каралган форма буенча бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәсен.

6. Идарә:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый (документларны карау срогы гаризаны теркәгән көннән алып 15 эш көненннән күбрәк булырга тиеш түгел);

в) күрсәтелгән документларга нигезләнеп Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма исәп-хисап белешмәсен әлеге боерыкка 12 нче кушымтада каралган форма буенча төзи һәм ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгына тапшыра.

7. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш коне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган Идарәләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган җыелма исәп-хисап

белешмәләре субсидияләр күчерү өчен нигез булып тора. Идарә субсидияләрне 5 эш коне эчендә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

8. Алынган субсидияләр субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән алтмыш кон эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

9. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

10. Тапшырган документларның дөреслеге очен җаваплылык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Идарәләрнең башлыкларына йөкләнә. Таләпләрне бозучыларга карата законнарда каралган җаваплылык чаралары күрелә.

11. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

________ елның ___номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
1 нче кушымта

## 2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип милекчелек формаларына бәйсез рәвештә үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) үсемлекчелек өлкәсендә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү өчен 2014 елда федераль бюджеттан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидияләр, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр).

2. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрен сайлап алу критерийлары:

а) үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату;

б) милек яки аренда шартларында авыл хуҗалыгы культураларын чәчү мәйданнарының булуы.

3. Субсидияләр бирү максатлары:

а) авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең 1 гектар чәчү мәйданына исәпләгәндә агротехник эшләр комплексын уздыру чыгымнарының бер өлешен каплау;

б) авыл хуҗалыгы производствосының экологик куркынычсызлыгы дәрәҗәсен арттыру;

в) туфракның уңдырышлылыгын һәм туфрак сыйфатын арттыру.

4. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өчен субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$V = П \times (135{,}6 + (2{,}36 \times У) + (45{,}17 \times И_{пп\ мр}))$

Монда:

V – күчерелергә тиешле субсидияләрнең күләме, сум;

П – гектарда исәпләгәндә, планлаштырылган чәчү мәйданы, алга таба ул № 4-СХ яки № 1-фермер формалары буенча “2014 ел уңышын алу өчен чәчү йомгаклары турында белешмәләр” статистик хисабында (алга таба – чәчү турында статистик хисап) расланачак ;

135,6 – бер гектар чәчү мәйданының минималь ставкасы, сум;

2,36 – ашлык берәмлекләрен җитештерүнең 1 центнерына ставка, сум;

У – авыл хуҗалыгы культураларының уртача уңдырышлылыгы, ул Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Авыл хуҗалыгы культураларын ашлык берәмлекләренә күчерү коэффициентларын раслау турында” 2013 елның 11 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгы нигезендә чәчү буенча статистик хисапларга һәм № 29-СХ формасы яки “Авыл хуҗалыгы культураларының уңышын җыю турында белешмәләр” № 1-фермерга нигезләнеп уртача соңгы 5

елда чәчүлекләрнең 1 гектарыннан алынган ашлык берәмлекләре центнерларында күрсәтелә. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүченең биш еллык тарихы булмаса, аның фактик эшчәнлек чоры, ә яңа төзелгән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өчен – соңгы 5 елда муниципаль район буенча уртача уңдырышлылык исәпкә алына.;

45,17 – чәчүлекнең бер гектарына җирләрнең уңрырышлылыгы буенча уртача ставка, сум;

$И_{пп.мр}$ – Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча туфрак уңдырышлылыгының уртача алынган индексы, ул әлеге тәртипкә кушымта нигезендә “Татарский” агрохимия хезмәте үзәге” Федераль дәүләт бюджет учреждениесе һәм “Әлмәт” агрохимия станциясе” Федераль дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан тапшырылган мәгълүматларга нигезләнеп Рф Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Россия Федерациясе субъектында туфрак уңдырышлылыгы күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында” 2013 елныц 11 гыйнварындагы 5 номерлы боерыгы белән расланган методика нигезендә билгеләнә.

5. Субсидия алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Татарстан Республикасы муниципаль районнарында ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гариза;

соңгы 5 ел өчен субсидия алучылар тарафыннан таныкланган № 4-СХ формасын яки № 1-фермер “Уңыш җыю өчен чәчү йомгаклары турында белешмәләр”не (алга таба – чәчү турында статистик хисап), № 29-СХ формасын яки № 2-фермер “Авыл хуҗалыгы культураларының уңышын җыю турында белешмәләр”ен (алга таба – уңыш җыю турында статистик хисап);

әлеге боерыкныж 11 кушымтасында каралган форма буенча бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәсен.

6. Идарә:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый (документларны карау срогы гаризаны теркәгән көннән алып 15 эш көненнннән күбрәк булырга тиеш түгел);

в) күрсәтелгән документларга нигезләнеп Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма исәп-хисап белешмәсен әлеге боерыкка 12 нче кушымтада каралган форма буенча төзи һәм ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгына тапшыра.

7. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш көне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган Идарәләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган җыелма исәп-хисап

белешмәләре субсидияләр күчерү өчен нигез булып тора. Идарә субсидияләрне 5 эш көне эчендә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

8. Алынган субсидияләр субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән алтмыш кон эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

9. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

10. Тапшырган документларның дереслеге өчен җаваплылык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Идарәләрнең башлыкларына йөкләнә. Таләпләрне бозучыларга карата законнарда каралган җаваплылык чаралары күрелә.

11. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын
җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә
бәйләнешсез ярдәм күрсәтү өчен Россия
Федерациясе субъектлары бюджетларына
федераль бюджет акчалары исәбеннән
субсидияләр бирү тәртибенә
кушымта

## Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләрнең күләмен исәпләү өчен туфрак уңдырышлылыгы индексы

| № т/б | Муниципаль район исеме | Агрохимия хезмәтләре белешмәләре буенча туфрак уңдырышлылыгы коэффициенты ($К_{мр}$) | Туфрак уңдырышлылыгы индексы ($И_{пп.мр}=71,05/К_{мр}$) |
|---|---|---|---|
| 1 | Әгерҗе | 75 | 0,9473 |
| 2 | Азнакай | 93 | 0,7640 |
| 3 | Аксубай | 82 | 0,8665 |
| 4 | Актаныш | 84 | 0,8458 |
| 5 | Алексеевск | 85 | 0,8359 |
| 6 | Әлки | 62 | 1,1460 |
| 7 | Әлмәт | 81 | 0,8772 |
| 8 | Апас | 78 | 0,9109 |
| 9 | Арча | 73 | 0,9733 |
| 10 | Әтнә | 66 | 1,0765 |
| 11 | Баулы | 84 | 0,8458 |
| 12 | Балтач | 76 | 0,9349 |
| 13 | Бөгелмә | 95 | 0,7479 |
| 14 | Буа | 86 | 0,8262 |
| 15 | Югары Ослан | 69 | 1,0297 |
| 16 | Биектау | 70 | 1,0150 |
| 17 | Чүпрәле | 87 | 0,8167 |
| 18 | Алабуга | 67 | 1,0604 |
| 19 | Зәй | 79 | 0,8994 |
| 20 | Зеленодольск | 74 | 0,9601 |
| 21 | Кайбыч | 79 | 0,8994 |
| 22 | Кама Тамагы | 76 | 0,9349 |
| 23 | Кукмара | 73 | 0,9733 |
| 24 | Лаеш | 76 | 0,9349 |
| 25 | Лениногорск | 82 | 0,8665 |
| 26 | Мамадыш | 70 | 1,0150 |
| 27 | Менделеевск | 71 | 1,0007 |
| 28 | Минзәлә | 68 | 1,0449 |
| 29 | Мөслим | 82 | 0,8665 |
| 30 | Түбән Кама | 73 | 0,9733 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 31 | Яңа Чишмә | 74 | 0,9601 |
| 32 | Нурлат | 72 | 0,9868 |
| 33 | Питрәч | 69 | 1,0297 |
| 34 | Балык Бистәсе | 72 | 0,9868 |
| 35 | Саба | 70 | 1,0150 |
| 36 | Сарман | 86 | 0,8262 |
| 37 | Спас | 60 | 1,1842 |
| 38 | Тәтеш | 82 | 0,8665 |
| 39 | Тукай | 81 | 0,8772 |
| 40 | Теләче | 69 | 1,0297 |
| 41 | Чирмешән | 80 | 0,8881 |
| 42 | Чистай | 72 | 0,9868 |
| 43 | Ютазы | 91 | 0,7808 |
| **ТР буенча уртача** | | **71,05** | **1,0000** |

2014 елның 24 февралендәге
33/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
2 нче кушымта

2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең элиталы орлык сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) сатып алынган элиталы орлыклар – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган Дәүләт селекция казанышлары реестрына кертелгән кулланылуы рөхсәт ителгән сортлар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен 2014 елда субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидияләр, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр).

2. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрне сайлап алу критерийлары:

а) үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату;

б) милек яки аренда шартларында авыл хуҗалыгы культураларын чәчү мәйданнарының булуы.

3. Субсидияләр бирү максатлары уңышны һәм үсемлекчелек продукциясен җитештерүне арттырудан гыйбарәт.

4. Авыл хуҗалыгы культураларының исемлеге һәм сатып алынган элиталы орлыклар өчен субсидияләр ставкалары Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана.

5. Сатып алынган элиталы орлыклар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидия алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Татарстан Республикасы муниципаль районнарында ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

б) авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын китерү шартнамәләрен;

в) түләүче банк таныклаган түләү йөкләмәсен;

г) товар-транспорт накладноен;

д) туры килү сертификатын;

е) карантин сертификаты һәм фитосанитар контроль актын (орлыкларны Татарстан Республикасыннан читтән керткәндә);

ё) әлеге боерыкка 13 нче кушымтада каралган форма буенча төзелгән бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәсен.

Тапшырылган документларның күчермәләрен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр таныклый.

6. Идарә:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый (документларны карау срогы гаризаны теркәгән көннән алып 15 эш көненнннән күбрәк булырга тиеш түгел);

в) күрсәтелгән документларга нигезләнеп, бирелергә тиешле субсидияләр турында авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тапшырган исәп-хисап белешмәсен таныклый һәм аны ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) тапшыра.

7. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш коне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лиңевой счетыннан авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

8. Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган бирелергә тиешле субсидияләр турындагы исәп-хисап белешмәләре субсидияләр күчерү өчен нигез була.

9. Алынган субсидияләр субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң Министрлыкның тиешле таләбен алган коннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

10. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

11. Тапшырган документларның дөреслеге өчен җаваплылык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Идарәләрнең башлыкларына йөкләнә. Таләпләрне бозучыларга карата законнарда каралган җаваплылык чаралары күрелә.

12. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

2014 елның 24 февралендәге
33/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы боерыгына
3 нче кушымта

2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләрен, интенсив типтагы бакчаларны утырту һәм карау чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләрен, интенсив типтагы бакчаларны утырту һәм карау чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидияләр, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр).

2. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрен сайлап алу критерийлары:

а) үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату;

б) милек яки аренда шартларында авыл хуҗалыгы культураларын чәчү мәйданнарының булуы.

3. Субсидияләр бирү максатлары җиләк-җимеш культураларының уңышын һәм аларны җитештерүне арттырудан гыйбарәт.

4. Күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләрен, интенсив типтагы бакчаларны утырту һәм карау өчен субсидияләр ставкалары Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 12 декабрендәге 1295 номерлы карарын 2013 елда гамәлгә ашыру чаралары турында” 2013 елның 15 гыйнварындагы 16 номерлы боерыгы белән расланган.

5. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Татарстан Республикасы муниципаль районнарында ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

б) подряд шартнамәсен (плдряд оешмасы җәлеп ителгән очракта);

в) күпьеллык үсемлекләрне утырту һәм карау эшләре башкарылу турында акт;

г) күпьеллык үсемлекләр утыртуның һәм аларны карауның фактик чыгымнары турында белешмәне;

д) әлеге боерыкка 14 нче кушымтада каралган форма буенча төзелгән бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәсен.

Тапшырылган документларның күчермәләрен авыл хуҗалыгы товарларын

җитештерүчеләр таныклый.

6. Идарә:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый (документларны карау срогы гаризаны теркәгән көннән алып 15 эш көненннән күбрәк булырга тиеш түгел);

в) күрсәтелгән документларга нигезләнеп, бирелергә тиешле субсидияләр турында авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тапшырган исәп-хисап белешмәсен таныклый һәм аны ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) тапшыра.

7. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш коне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лиңевой счетыннан авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

8. Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган бирелергә тиешле субсидияләр турындагы исәп-хисап белешмәләре субсидияләр күчерү өчен нигез була.

9. Алынган субсидияләр субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

10. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

11. Тапшырган документларның дөреслеге өчен җаваплылык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Идарәләрнең башлыкларына йөкләнә. Таләпләрне бозучыларга карата законнарда каралган җаваплылык чаралары күрелә.

12. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

2014 елның 24 февралендәге
33/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
4 нче кушымта

2014 елда файдаланылмый торган иске бакчаларны төпләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны рекультиваңияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) файдаланылмый торган иске бакчаларны төпләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны рекультиваңияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидияләр, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр).

2. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрен сайлап алу критерийлары:

а) үсемлекчелек продукңиясен җитештерү һәм сату;

б) милек яки аренда шартларында авыл хуҗалыгы культураларын чәчү мәйданнарының булуы.

3. Субсидияләр бирү максатлары бакчаларны яңартудан, аларның мәйданнарын саклап калудан һәм арттырудан, җиләк-җимеш культураларының уңышын һәм аларны җитештерүне арттырудан гыйбарәт.

4. Утырту елыннан алып исәпләгәндә 30 елдан арткан бакчаларны төпләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны рекультиваңияләү өчен субсидияләр ставкалары Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 12 декабрендәге 1295 номерлы карарын 2013 елда гамәлгә ашыру чаралары турында” 2013 елның 15 гыйнварындагы 16 номерлы боерыгы белән (2013 елның 17 декабрендәге 476 номерлы үзгәрешләрне дә кертеп) расланган.

5. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Татарстан Республикасы муниципаль районнарында ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

б) тамырлардан арындырылган мәйданнарда яңа бакча утырту проектын;

в) подряд шартнамәсен (плдряд оешмасы җәлеп ителгән очракта);

г) иске бакчаларның яше һәм мәйданы турында мәгълүматны үз эченә алган хуҗалыкларның еллык хисапларын;

д) бакчаларны төпләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны рекультивацияләү эшләре башкарылу турында акт;

е) бакчаларны төпләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны

рекультивацияләүнең фактик чыгымнары турында белешмәне;

ж) әлеге боерыкка 15 нче кушымтада каралган форма буенча төзелгән бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәсен.

Тапшырылган документларның күчермәләрен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр таныклый.

6. Идарә:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый (документларны карау срогы гаризаны теркәгән көннән алып 15 эш көненнннән күбрәк булырга тиеш түгел);

в) күрсәтелгән документларга нигезләнеп, бирелергә тиешле субсидияләр турында авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тапшырган исәп-хисап белешмәсен таныклый һәм аны ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) тапшыра.

7. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш коне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

8. Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган бирелергә тиешле субсидияләр турындагы исәп-хисап белешмәләре субсидияләр күчерү өчен нигез була.

9. Алынган субсидияләр субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

10. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

11. Тапшырган документларның дөреслеге өчен җаваплылык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Идарәләрнең башлыкларына йөкләнә. Таләпләрне бозучыларга карата законнарда каралган җаваплылык чаралары күрелә.

12. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

2014 елның 24 февралендәге
33/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
5 нче кушымта

2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү очен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөт чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) (алга таба – авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр) сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөткә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплау өчен 2014 елда субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидияләр, сөт).

2. Субсидияләр бирү максаты сөт җитештерү өчен уңай икътисадый шартлар тудырудан гыйбарәт.

3. Субсидияләр милекләрендә һәм (яки) аренда хокукында сыерлары булган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөткә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү турында мөрәҗәгать иткән айның 1 числосына бирелә.

4. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

2013 елда 100 баш сыерга исәпләгәндә кимендә 70 бозау туу тәэмин ителгәндә;

2014 елда, 2013 елның шул ук чоры белән чагыштырып караганда, сөт җитештерү күләмнәренең кимүенә юл куелмаганда;

2014 елда, 2013 елның шул ук чоры белән чагыштырып караганда, сыерларның сөт бирүчәнлегенең кимүенә юл куелмаганда. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрдә сыерларның уртача сөт продуктивлыгы 7000 кг һәм аннан да күбрәк булганда 2014 елда сыерларның сөт продуктивлыгын, 2013 елның шул ук чоры белән чагыштырып караганда, иң күбе 5 %ка киметү рөхсәт ителә;

сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сөттә майлылык кимендә 3,4 % һәм аксым кимендә 3,0 % булганда.

5. Товар сөтне сатуны һәм (яки) үзендә эшкәртүне башкаручы әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән шартларга туры килә торган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә 1 литр (килограмм) товар сөткә чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) билгели торган ставкалар буенча

квартал саен түбәндәгечә бирелә:

а) агымдагы елның икенче һәм өченче кварталларында агымдагы елның узган кварталында сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сөтнең физик авырлыгы күләмнәреннән чыгып;

б) агымдагы елның дүртенче кварталында агымдагы елның өченче кварталында һәм агымдагы елның октябрь, ноябрь айларында сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сөтнең физик авырлыгы күләмнәреннәе чыгып.

6. Субсидиянең күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_i = W_{Hi} + W_{Fi}$$

монда:

$W_{Hi}$ – авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчегә тапшырыла торган югары сортлы сөткә субсидия күләме;

$W_{Fi}$ – авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчегә тапшырыла торган беренче сортлы сөткә субсидия күләме;

7. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчегә тапшырыла торган югары сортлы сөткә субсидия күләме ($W_{Hi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{Hi} = S_H x V_{Hi}$$

монда:

$S_H$ – хисап чорында сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән югары сортлы сөтнең күләмнәреннән чыгып Министрлык тарафыннан раслана торган югары сортлы сөтнең 1 литрына (килограммына) ставка;

$V_{Hi}$ – сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән югары сортлы сөтнең күләме.

8. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчегә тапшырыла торган беренче сортлы сөткә субсидия күләме ($W_{Fi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{Fi} = S_F x V_{Fi}$$

монда:

$S_F$ – хисап чорында сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән беренче сортлы сөтнең күләмнәреннән чыгып Министрлык тарафыннан раслана торган беренче сортлы сөтнең 1 литрына (килограммына) ставка;

$V_{Fi}$ – сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән беренче сортлы сөтнең күләме.

9. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Татарстан Республикасы муниципаль районнарында ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

б) әлеге боерыкка 16 нчы кушымтада каралган форма буенча физик

авырлыктагы товар сөтнең авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче тарафыннан сатылуы һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелүе фактынраслый торган документлар реестрын.

Үзендә сөт эшкәртү мөмкинлекләре булган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр хуҗалык эчендә йөри торган накладнойларның (сөт ташу өчен) таныкланган күчермәләрен, үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән товар сөтнең планлаштырылган үзкыйммәте күрсәтелгән бухгалтерия белешмәсен һәм сөт продукциясенә куллану өчен яраклылык сертификатын тапшыралар;

в) федераль дәүләт статистика күзәтчелегенең формалары буенча терлекчелек продукциясен җитештерү һәм терлекнең баш саны турында белешмәләрнең күчермәләрен: авыл хуҗалыгы оешмалары өчен “Терлекчелекнең торышы турында белешмәләр” № 24-СХ формасы (еллык), крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм индивидуаль эшкуарлар өчен “Терлекчелек продукциясен җитештерү һәм терлекнең һәм кош-кортның баш саны турында белешмәләр” № 3-фермер яки 3-фермер (кыскача) формасы, аларда 2013 елның 1 гыйнварына һәм 2014 елның 1 гыйнварына дәүләт статистика органнары тарафыннан хисапларның кабул ителүе турында тамга булырга тиеш;

г) федераль дәүләт статистика күзәтчелегенең формалары буенча субсидияләр бирү турында мөрәҗәгать иткән айның 1 числосына терлекчелек продукциясен җитештерү һәм терлекнең баш саны турында белешмәләрнең күчермәләрен: авыл хуҗалыгы оешмалары өчен “Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм терлекнең баш саны турында белешмәләр” № П-1(СХ) формасы, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм индивидуаль эшкуарлар өчен “Терлекчелек продукциясен җитештерү һәм терлекнең һәм кош-кортның баш саны турында белешмәләр” № 3-фермер (кыскача) формасы, аларда дәүләт статистика органнары тарафыннан хисапларның кабул ителүе турында тамга булырга тиеш;

д) 2014 елның бер кварталында һәм 2013 елның шул ук чорында Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөткә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү өчен сыерларның баш саны, сөт җитештерү, сөт продуктивлыгы һәм бозаулар туу буенча әлеге боерыкка 21 нче кушымтада каралган форма буенча кварталлык күрсәткечләрне;

е) бухгалтерлык хисапларына нигезләнеп әлеге боерыкка 25 нче кушымтада каралган форма буенча авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән терлекчелек продукциясенең сыйфаты турындагы белешмәләрне һәм әлеге боерыкка 26 нчы кушымтада каралган форма буенча 2014 елда сөт җитештерү, сыерларның сөт продуктивлыгы һәм 100 баш сыердан бозаулар туу исәбе хакында белешмәләрне;

ж) әлеге пунктның “б” пунктчасында күрсәтелгән документлар нигезләнеп, 2014 елның кварталында сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөткә чыгымнарының бер өлешен федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен әлеге боерыкка 19 нчы кушымтада каралган форма буенча исәп-хисап белешмәләрен;

з) 2014 елда сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр

(килограмм) товар сөткә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләре чыгымнарының бер олешен каплау очен федераль бюджеттан субсидияләр бирү очен сыерларның баш саны, сөт җитештерү, сөт продуктивлыгы һәм бозаулар туу буенча әлеге боерыкка 23 нче кушымтада каралган форма буенча еллык күрсәткечләрне.

6. Идарә:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый. Документларны карау срогы гаризаны теркәгән көннән алып 15 эш көненнән күбрәк булырга тиеш түгел;

в) әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән документларга нигезләнеп, Министрлык тарафыннан расланган формалар буенча түбәндәгеләрне төзи һәм Министрлыкка тапшыра:

әлеге боерыкка 17 нче кушымтада каралган форма буенча муниципаль районга алганда физик авырлыгында товар сөт сатуның һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрүнең җыелма реестрларын;

әлеге боерыкка 22 нче кушымтада каралган форма буенча Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә 2014 ел кварталында сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөт чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен сыерларның баш саны, сөт җитештерү, сөт продуктивлыгы һәм бозаулар туу буенча җыелма кварталлык күрсәткечләрен;

әлеге боерыкка 20 нче кушымтада каралган форма буенча муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең 2014 ел кварталында сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөт чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләрен;

әлеге боерыкка 25 нче кушымтада каралган форма буенча авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче тарафыннан 2014 елда сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән терлекчелек продукцияләренең сыйфаты турында белешмәләрне;

әлеге боерыкка 26 нчы кушымтада каралган форма буенча 2014 елда сөт җитештерү, сыерларның сөт бирүе һәм 100 баш сыерга туры килә торган бозаулар саны турында мәгълүматны;

әлеге боерыкка 24 нче кушымтада каралган форма буенча Татарстан Республикасы муниципаль районының авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләре буенча 2014 елда сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) товар сөт чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен сыерларның баш саны, сөт җитештерү, сөт продуктивлыгы һәм бозаулар туу буенча җыелма еллык күрсәткечләрен.

11. Азык-төлек базарын үстерү бүлеге, Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-

төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең җыелма реестрларына нигезләнеп, ел саен әлеге боерыкка 18 нче кушымтада каралган форма буенча Татарстан Республикасының җыелма реестрын төзи һәм аны хисап аеннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенә тапшыра.

12. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш көне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лиңевой счетыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекчәләрендә ачылган Идарәләрнең лицевой счетларына күчерә.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган әлеге боерыкка 20 нче кушымтада каралган форма буенча Татарстан Республикасы буенча бирелергә тиешле субсидияләр турындагы җыелма исәп-хисап белешмәләре субсидияләр күчерү өчен нигез була.

13. Алынган субсидияләр субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

14. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

15. Тапшырган документларның дөреслеге өчен җаваплылык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә йөкләнә. Таләпләрне бозучыларга карата законнарда каралган җаваплылык чаралары күрелә.

16. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

2014 елның 24 февралендәге
33/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
6 нчы кушымта

# 2014 елда нәселле терлекчелеккә ярдәм итү өчен федераль бюджет акчалары исәбеинәи субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип ярдәмче шәхси хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, нәсел заводларына, нәсел репродукторларына, авыл хуҗалыгы терлеген ясалма орлыкландыру оешмаларына нәселле терлекчелеккә, шул исәптән ит бирә торган мөгезле эре терлеккә ярдәм итү өчен (алга таба – терлекчелеккә ярдәм итү) 2014 елда федераль бюджеттан субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр түбәндәге юнәлешләр буенча бирелә:

а) нәселле терлекчелеккә ярдәм итү, шул исәптән:

ит мөгезле эре терлегеннән тыш авыл хуҗалыгы эре терлегенең нәселле ана башларын асрау;

нәсел калдыру сыйфаты буенча тикшерелгән яки мондый сыйфатны бәяләү проңессындагы 16 айдан зуррак сөт нәсел үгезләрен (алга таба - сөт нәсел үгезләре) тоту;

сөт нәсел үгезләрен сатып алу, шул исәптән импорт буенча;

сөт нәселле мөгезле эре яшь терлекне сатып алу, шул исәптән импорт буенча;

сөт нәсел үгезләренең нәселлек сыйфаты буенча тикшерелгән орлыкларын сатып алу, шул исәптән импорт буенча;

сот нәселле мөгезле эре терлегенең эмбрионнарын сатып алу, шул исәптән импорт буенча;

б) ит нәселле мөгезле эре терлегенә ярдәм итү, шул исәптән:

ит мөгезле эре терлегенең нәселле ана башларын асрау;

нәсел калдыру сыйфаты буенча тикшерелгән яки мондый сыйфатны бәяләү проңессындагы 16 айдан зуррак ит нәсел үгезләрен (алга таба - ит нәсел үгезләре) тоту;

ит нәсел үгезләрен сатып алу, шул исәптән импорт буенча;

ит нәселле мөгезле эре яшь терлеген сатып алу, шул исәптән импорт буенча;

ит нәсел үгезләренең нәселлек сыйфаты буенча тикшерелгән орлыкларын сатып алу, шул исәптән импорт буенча;

ит нәселле мөгезле эре терлегенең эмбрионнарын сатып алу, шул исәптән импорт буенча.

3. Субсидияләр бирү максаты нәселле терлекнең баш санын арттырудан,

артым алудан һәм авыл хуҗалыгы терлеген ясалма орлыкландыруны арттырудан гыйбарәт.

4. Терлекчелеккә ярдәм итү өчен акчалар түбәндә күрсәтелгән максатлар өчен Россия Федерациясе субъектларына каралган акчалар кысаларында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан билгеләнгән ставкалар буенча бирелә:

а) Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары тәкъдиме буенча Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә - шартлы рәвештә 1 баш ставкасы буенча (сөт һәм ит өчен терлек үрчетүдә - хисап финанс елында тере бозау китергән 1 башка исәпләгәндә) авыл хуҗалыгы терлегенең нәселле ана башын асрауга. Авыл хуҗалыгы терлегенең нәселле ана башын шартлы рәвештә алынган баш исәбенә күчерү коэффициенты Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнә;

б) Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары тәкъдиме буенча Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән авыл хуҗалыгы терлеген ясалма орлыкландыру оешмаларына – 1 баш ставкасыннан чыгып нәсел үгезләрен асрауга;

в) авыл хуҗалыгы терлеген ясалма орлыкландыра торган оешмаларга – дәүләт ннәсел регистрында теркәлгән нәселле көтүләрдән нәсел үгезләрен сатып алуга, шул исәптән 1 кг тере масса ставкасыннан импорт буенча;

г) авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә - дәүләт ннәсел регистрында теркәлгән нәселле көтүләрдән ит нәселле мөгезле эре яшь терлеген сатып алуга, шул исәптән 1 кг тере масса ставкасыннан импорт буенча;

д) авыл хуҗалыгы терлеген ясалма орлыкландыра торган оешмаларга – нәселлек сыйфаты тикшерелгән нәсел үгезләренең орлыкларын 1 доза ставкасы буенча сатып алуга, шул исәптән импорт буенча;

е) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән авыл хуҗалыгы терлеген ясалма орлыкландыру оешмаларына – сөт мөгезле эре терлеге эмбрионнарын 1 данәгә исәпләнгән ставка буенча сатып алуга.

5. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

б) әлеге боерыкка 27 нче кушымтада каралган форма буенча исәп-хисап белешмәсен;

в) фермада терлекнең һәм кош-кортның әйләнеше турында хуҗалык эчендә йөри торган хисапның күчермәсен;

г) федераль дәүләт статистик күзәтчелегенең № 24-СХ (еллык) формасы буенча терлекчелекнең торышы турында белешмәләрнең күчермәсен;

сөт нәсел үгезләрен сатып алу өчен, шул исәптән импорт буенча, сөт

нәселле мөгезле эре яшь терлеген сатып алу өчен, шул исәптән импорт буенча, ит нәсел үгезләрен сатып алу өчен, шул исәптән импорт буенча, ит нәселле мөгезле эре яшь терлеген сатып алу өчен, шул исәптән импорт буенча, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Министрлыкка түбәндәге документлар тапшыралар:

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

б) әлеге боерыкка 28 нче кушымтада каралган форма буенча исәп-хисап белешмәсен;

в) аванс түләүләрен дә кертеп, товарлар өчен түләү буенча банк өземтәләренең һәм түләү йөкләмәләренең субсидияләр алучы һәм түләүче банк тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

г) шартнамә, счет-фактура, накладной яки гурт ведомостенең, нәсел эшләре белән шөгыльләнә торган оешма биргән нәсел таныклыкларының яки паспортларының (10 баштан артык сатып алынса, нәсел таныклыкларының яки паспортларының реестры тапшырыла) күчермәсен;

д) фермада терлекнең һәм кош-кортның әйләнеше турында хуҗалык эчендә йөри торган хисапның күчермәсен;

ж) федераль дәүләт статистик күзәтчелегенең № 24-СХ (еллык) формасы буенча терлекчелекнең торышы турында белешмәләрнең күчермәсен.

нәселле мөгезле эре яшь терлеген лизинг шартнамәләре, нәселле мөгезле эре яшь терлеген өлешләп түләү шарты белән сату-алу шартнамәләре буенча сатып алган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр нәселле мөгезле эре яшь терлеген сатып алуга субсидияләрне банк тарафыннан таныкланган түләү йөкләмәләрен һәм банк өземтәләрен тапшырганнан соң алалар.

сөт нәсел үгезләре орлыкларын сатып алу өчен, шул исәптән импорт буенча, ит нәсел үгезләре орлыкларын сатып алу өчен, шул исәптән импорт буенча, сөт нәселле мөгезле эре терлеге эмбрионнарын сатып алу өчен, шул исәптән импорт буенча, ит нәселле мөгезле эре терлеге эмбрионнарын сатып алу өчен, шул исәптән импорт буенча,

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

б) әлеге боерыкка 28 нче кушымтада каралган форма буенча исәп-хисап белешмәсен;

в) аванс түләүләрен дә кертеп, товарлар өчен түләү буенча банк өземтәләренең һәм түләү йөкләмәләренең субсидияләр алучы һәм түләүче банк тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

г) шартнамә, счет-фактура, накладной күчермәсен.

Тапшырылган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан таныклана.

6. Министрлык:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 6 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый (документларны карау срогы гаризаны теркәгән көннән алып 15 эш көненнән күбрәк булырга тиеш түгел);

в) әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлардагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерә.

7. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш көне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекчәләрендә ачылган Идарәләрнең лицевой счетларына күчерә.

8. Алынган субсидияләр субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

9. Министрлык бюджет акчаларын бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең аларны алучылар тарафыннан үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

10. Тапшырган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидияләр алучыларга йөкләнә. Таләпләрне бозучыларга карата законнарда каралган җаваплылык чаралары күрелә.

16. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

2014 елның 24 февралендәге
33/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы боерыгына
7 нче кушымта

2014 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләү чыгымнарының бер олешен каплау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы иминләштерүен башкарырга лиңензияләре булган һәм ган иминләштерү оешмалары белән төзелгән шартнамәләре буенча 2014 елда федераль бюджеттан авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү механизмын билгели. Субсидияләр, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүченең гаризасына нигезләнеп, исәпләнгән иминият премиясенең 50 проңенты күләмендә иминләштеү оешмаларының исәп-хисап счетларына күчерелә.

2. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрне сайлап алу критерийлары:

а) авыл хуҗалыгы  продукциясен җитештерү;

б) авыл хуҗалыгы культураларын чәчү мәйданнарының булуы (дәүләт ярдәме белән башкарыла торган авыл хуҗалыгы культураларының уңышын иминләштерү шартнамәләре буенча);

в) авыл хуҗалыгы терлеге һәм кош-корт башларының милектә һәм (яки) арендалау хокукында булуы (дәүләт ярдәме белән башкарыла торган авыл хуҗалыгы терлеген иминләштерү шартнамәләре буенча).

3. Субсидияләр авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсе буенча исәпләнгән иминият премиясен түләү чыгымнарын бер өлешен каплау белән бәйле максатларга бирелә:

а) үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы культуралары (бөртекле, бөртекле-кузаклы, май, техник, азык, бахча культуралары, бәрәңге, яшелчәләр, виноградлыклар, җимеш, җиләк һәм чикләвек агачлары, куаклары, колмак һәм чәй плантацияләре) уңышының югалуы (юкка чыгуы), күпьеллык үсемлекләр үсентеләренең (виноградлыклар, җимеш, җиләк һәм чикләвек агачлары, куаклары, колмак һәм чәй плантаңияләре) югалуы (юкка чыгуы) түбәндәге вакыйгалар аркасында барлыкка килү очрагына:

табигать күренешләренең авыл хуҗалыгы продукңиясен җитештерү өчен куркынычлы булган йогынтысы (атмосферадага, туфрактагы корылык, коры җил, кырау төшү, өшү, парлану, боз яву, тузан бураны, боз яту, су басу, туфракның артык дымлануы, көчле җил, гарасат, җир тетрәү, кар төшү, сил, табигый янгын);

зыянлы организмнарның үтеп керүе һәм (яки) таралуы, әгәр мондый вакыйгалар эпифитотик характерда булса;

ябылган туфракта яки мелиорацияләнә торган җирләрдә үстерелә торган авыл хуҗалыгы культураларын иминләштергәндә табигать бәла-казалары аркасында электр, җылылык, су белән тәэмин итү бозылу;

б) терлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы терлегенең (мөгезле эре терлек (үгезләр, эш үгезләре, сыерлар) мөгезле вак терлек (кәҗәләр, сарыклар), дуңгызлар, атлар), куяннар, йонлы хайваннар, йомырка сала торган кош һәм ит кошы (казлар, күркәләр, тавыклар, бытбылдыклар, үрдәкләр, мисыр тавыклары), бройлер тавыклар, бал кортлары күчләре) югалуы (үлүе) түбәндәге вакыйгалар аркасында барлыкка килү очрагына:

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән йогышлы хайван аврулары, күпләп агулану;

табигать бәла-казалары (яшен сугу, җир тетрәү, тузан бураны, гарасат, көчле буран, буран, су басу, ташлар төшү, кар төшү, сил, җир убылу);

әгәр авыл хуҗалыгы терлеген асрау шартлары электр, җылылык энергиясеннән, судан мәҗбүри файдалануны күз алдында тотса, табигать бәла-казалары аркасында электр, җылылык, су белән тәэмин итү бозылу;

янгын.

4. Субсидия алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

әлеге боерыкка 35 нче кушымтада каралган форма буенча иминләштерү оешмасының исәп-хисап счетына максатчан акчалар күчерү турында гаризаны (алга таба – гариза);

авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсе һәм түләү йөкләмәсе яки авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче тарафыннан иминият премиясенең 50 процентны түләнүне раслый торган башка документ нигезендә төзелгән максатчан акчаларның күләме турында әлеге боерыкка 29, 30, 31, 32 нче кушымталарда каралган форма буенча белешмәне;

авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсенең күчермәсен;

авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсе буенча 50 процент иминият премиясен (иминият кертемен) түләү турында түләүче банк тарафыннан таныкланган түләү йөкләмәсенең яки башка документның күчермәсен;

иминләштерү оешмасының түли алуы турында хисабыннан авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсен төзегәндә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчегә иминләштерү оешмасы биргән норматив күләменә караганда түли алу маржының чынбарлыктагы күләменең кимендә 30 процентыннан артуы турында өземтәне яисә авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсе буенча иминият түләвенең бер өлешен иминләштерү оешмасы тарафыннан өстәмә иминләштерелүе турында, шул исәптән өстәмә иминләштерә торган иминләштерү оешмасының (иминләштерү оешмаларының) исеме, өстәмә иминләштергәндә тапшырылган риск (рисклар) буенча иминият түләүләренең өлеше (күләме) турында белешмәләр, өстәмә иминләштерү шартнамәсенең (шартнамәләренең) реквизитлары (төзү датасы, шартнамә номеры, өстәмә иминләштерүнең формасы) турында мәгълүматны үз эченә алган документны.

Тапшырылган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товарларын

житештерүчеләр тарафыннан таныклана.

5. Субсидияләр түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

а) авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсе авыл хуҗалыгы товарларын житештерүче тарафыннан авыл хуҗалыгы иминләштерүен башкарырга лицензиясе булган һәм Россия Федерациясе Хокүмәтенең “Авыл хуҗалыгы товарларын житештерүчеләрнең авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 22 декабрендәге 1371 номерлы карары белән расланган Авыл хуҗалыгы товарларын житештерүчеләрнең авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 5 пунктында каралган таләпләргә җавап бирә торган иминләштерү оешмасы белән төзелгән булса;

иминләштерү оешмасы үз акчаларының һәм алган йөкләмәләренең нормативларын үтәсә (түли алу маржының чынбарлыктагы күләменең Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгели торган тәртиптә исәпләнә торган норматив күләменә караганда кимендә 30 процентка артуы (авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсен төзегән көнгә кадәрге хисап чорында бирелгән хисап мәгълүматлары буенча) яки өстәмә иминләштерү шартнамәсе булса, соңгысы нигезендә иминләштерү оешмасы, үзенең финанс тотрыклылыгын бәяләүне исәпкә алып иминләштерү шартнамәләре буенча иминият түләүләре рискының бер өлешен иминләштергән (түли алу маржының чынбарлыктагы күләменең норматив күләменә караганда кимендә 30 процентка артуы;

иминлштерү оешмасы дәүләт ярдәме белән башкарыла торган авыл хуҗалыгы иминләштерүен башкаручы иминләштерүчеләр берләшмәсенең әгъзасы булып торса;

б) авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсе 2014 елга авыл хуҗалыгы иминләштерүе планында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культураларының һәм күпьеллык үсемлекләр утыртмаларының уңышына кагылышлы итеп авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләре тарафыннан авыл хуҗалыгы культуралары һәм күпьеллык үсемлекләр үстерелә торган җир кишәрлекләренең бөтен территориясенә төзелгән булса;

в) авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсе түбәндәге срокларга төзелгән:

күпьеллык үсемлекләрдән тыш авыл хуҗалыгы культуралары буенча – аларны чәчү яки утырту төгәлләнгәннән соң 15 календарь көннән дә соңга калмыйча;

күпьеллык үсемлекләр буенча – аларның үсүе тукталганга (кышкы халәтенә күчүенә) кадәр;

г) авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсе 2014 елга авыл хуҗалыгы иминләштерүе планында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы терлегенә кагылышлы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрдә булган барлык аерым төр авыл хуҗалыгы терлегенең барлык баш санына төзелгән булса;

д) авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсе авыл хуҗалыгы терлегенә кагылышлы кимендә бер елга төзелгән;

е) авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсе үз көченә кергән һәм авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче әлеге шартнамә буенча исәпләнгән иминият премиясенең 50 процентын түләгән;

ж) авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсе, Россия Федерациясе Граждан кодексының 958 статьясында каралган очраклардан тыш, төзелгән срогы җиткәнче туктатыла алмый;

з) авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсендә иминият бәясенең 80 процентыннан ким булмаган күләмендә иминият суммасы билгеләнгән;

и) иминләштергәндә дәүләт ярдәме күрсәтелә торган авыл хуҗалыгы рискларын иминләштергәндә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүченең (иминләштертүченең) катнашуы авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәсе буенча иминият суммасының кырык процентыннан артып китми. Мондый өлеш иминият тарифларын билгеләгәндә исәпкә алына. Күрсәтелгән рискларны иминләштергәндә иминләштертүченең катнашуы дигәндә зыянның бер өлешен иминләштертүченең үзе каплавы аңлашыла. Күрсәтелгән рискларны иминләштергәндә иминләштертүченең катнашу әлеше кысаларындагы зыян иминләштерүче тарафыннан кире кайтарылмый;

к) иминият тарифларын исәпләгәндә кулланыла торган һәм турыдан туры иминләштертүчеләргә һәм файда алучыларга иминият һәм компенсация түләүләрен башкару өчен билгеләнгән иминият премиясенең бер өлеше сиксән проценттан ким була алмый;

л) авыл хуҗалыгы культурасы уңышының иминият бәясен һәм аларны югалту (юкка чыгу), күпьеллык үсемлекләрнең утыртмаларын югалту (юкка чыгу), авыл хуҗалыгы терлеген югалту (үлүе) күләмен исәпләү Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланган методика буенча башкарыла.

м) субсидияләрне исәпләү Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган ставкалар буенча башкарыла.

6. Министрлык:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш, һәм кабул ителгән документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көненнән артмаган вакыт эчендә гаризаны карауга алулары турында яки аны алудан сәбәпләре күрсәтелгән баш тарту турында язма хәбәрнамә юллый;

б) әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый. Документларны карау вакыты гаризаны теркәгән көннән алып 10 эш көненнән артырга тиеш түгел;

в) әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә тапшырылган документлардагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерә.

7. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш көне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча

идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан иминләштерү оешмаларының исәп-хисап счетларына күчерә.

8. Субсидияләр бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

тулы булмаган документлар комплекты тапшырылу;

тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләрнең булуы;

тиешле елга Министрлыкка бу максатларга каралган бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы.

9. Алынган субсидияләр субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

10. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

11. Тапшырган документларның дөреслеге өчен җаваплылык авыл хуҗалыгы иминләштерүен башкаручы иминләштерү оешмаларына. авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Идарәләр башлыкларына йөкләнә. Таләпләрне бозучыларга карата законнарда каралган җаваплылык чаралары күрелә.

12. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

2014 елның 24 февралендәге
33/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы боерыгына
8 нче кушымта

Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына 2 елдан алып 15 елга кадәрге срокка алынган инвестиция кредитлары буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен 2014 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2004 – 2014 елларда 2 елдан алып 15 елга кадәрге срокка россия кредит оешмаларында алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларында алынган заемнар буенча (алга таба – субсидияләр, заемнар) процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау максатларында 2014 елда Россия Федерациясе бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирүне регламентлаштыра.

2. Субсидияләр авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына (алга таба – заем алучылар) бирелә.

3. Субсидияләр түбәндәгеләр буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга бирелә:

а) түбәндәгеләр тарафыннан алынган инвестиция кредитлары (заемнары), буенча:

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмалары, крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары тарафыннан түбәндәге чорларда төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2004 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 2 елдан алып 8 елга кадәр срокка – җиһазлар, махсуслаштырылган транспорт, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә махсус техника, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ-мотор ягулыгына күчерү өчен җиһазлар һәм нәселлек продукцияләрен (материалын) сатып алуга, шулай ук күпьеллык үсемлекләр утыртуга, күпьеллык үсемлекләр өчен ялгау комплекларын төзүгә, реконструкцияләүгә, терлекчелек комплексларын (фермаларын), терлекчелек, азык җитештерү объектларын,

бәрәңге базларын, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, ябык грунтта җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен җитештерү буенча теплица комплексларын, җитенне һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, ит саклау урыннарын, авыл хуҗалыгы терлеген һәм сотне кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү пунктларын, моңа ит һәм сөт продукциясен суыту да керә, төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, шулай ук протеиннарга бай авыл хуҗалыгы культураларын (кытай борчагы, бодай, арыш, кукуруз, рапс, нут һәм сарго) тирән эшкәртү объектларын төзүгә;

2004 елның 1 гыйнварыннан алып 2008 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 2 елдан алып 8 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл хуҗалыгы техникасы сатып алуга;

2009 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка – авыл җирендә яшәүче һәм эшләүче гражданнар өчен торак төзүгә;

2010 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә яңгыр яудыру һәм су сибү, насос станцияләре машиналарын, җайланмаларын һәм аппаратларын сатып алуга;

2008 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) тарафыннан төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл хуҗалыгы техникасы сатып алуга;

оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмалары, крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары тарафыннан түбәндәгеләргә төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2010 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 10 елга кадәр срокка: бөртекле һәм май культураларын хәзерләп кую, саклау һәм күчерү өчен куәтләр төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә бөртекле һәм май культураларын хәзерләп кую, саклау һәм күчерү өчен җиһазлар сатып алуга (монтаж һәм көйләп җибәрү эшләрен дә кертеп) ;

оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмалары тарафыннан төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2009 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка – шикәр заводларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә;

2010 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка – шикәр чөгендеренең борчакландырылган орлыкларын җитештерү заводларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә;

2011 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка – авыл хуҗалыгы үсемлекләре орлыкларын әзерләү һәм эшкәртү буенча мелиоратив системалар, заводлар, комплекслар төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм торгызуга;

оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә товар (сәнәгать) балык үрчетү белән шөгыльләнүче оешмалар тарафыннан 2007 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, түбәндәге срокка срокка төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

5 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә товар (сәнәгать) балык үрчетү өчен нәселле балык материалын, техниканы һәм җиһазларны сатып алуга;

8 елга кадәр срокка – товар (сәнәгать) балык үрчетүне башкару буенча комплекслар (фермалар) төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә;

оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә йортлаштырылган балык төрләрен һәм токымнарын үрчетү белән шөгыльләнүче оешмалар тарафыннан 2012 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, түбәндәге срокка срокка төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

5 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә йортлаштырылган балык төрләрен һәм токымнарын үрчетү өчен нәселле балык материалын, техниканы һәм җиһазларны сатып алуга;

8 елга кадәр срокка – йортлаштырылган балык төрләрен һәм токымнарын үрчетүне башкару буенча комплекслар (фермалар) төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә;

б) 2013 елдан башлап төзелгән инвестицияле кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмалары, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, агросәнәгать комплексы оешмалары тарафыннан 2 елдан алып 8 елга кадәр срокка төзелгән:

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә үсемлекчелек тармакларын үстерү максатларында бәрәңге базларын, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, ябык грунтта җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен җитештерү буенча теплица комплексларын, ашлык сугу, ипи пешерү һәм май сәнәгате предприятиеләрен, шикәр заводларын, яшелчә, җиләк-җимеш, бәрәңге продукциясен эшкәртү куәтләрен, җитенне һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, авыл хуҗалыгы үсемлекләренең орлыкларын хәзерләү комплексларын, шикәр чөгендеренең

борчакландырылган орлыкларын җитештерү заводларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, протеиннарга бай авыл хуҗалыгы культураларын тирән эшкәртү объектларын, бөртекле һәм май культураларын хәзерләп кую, саклау һәм күчерү, күпьеллык үсемлекләрне утырту һәм карау куәтләрен төзүгә, күпьеллык үсемлекләр өчен ялгау комплексларын төзү һәм реконструкцияләүгә;

мелиорация системаларын төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм торгызуга (мелиорация системаларын төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм торгызуга алынган инвестиция кредитларын субсидияләү 2013 елның 31 декабренә кадәр гамәлгә ашырыла);

үсемлекчелектә файдаланыла торган авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын сатып алуга (код ОКП 472000, 473000);

терлекчелектә файдаланыла торган авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын сатып алуга (код ОКП 472000, 473000);

терлекчелектә (шул исәптән авыл хуҗалыгы терлеген сату буенча һәм үсемлекчелектә логистик үзәкләр төзүгә;

ит өчен терлек үрчетүне үстерү буенча хуҗалык эшчәнлеген тәэмин итү максатларында файдаланыла торган авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын; үз ана башлар көтүен булдыру өчен ит токымнары мөгезле эре терлегенең товар ремонт яшь терлеген сатып алуга;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмалары (ит өчен терлек үрчетү белән шөгыльләнүче оешмалардан тыш) тарафыннан 2 елдан алып 8 елга кадәр срокка – терлекчелек комплексларын (фермаларын), объектларын, ит саклау урыннарын, авыл хуҗалыгы терлеген һәм сотне кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү пунктларын (моңа ит һәм сөт продукциясен суыту да керә), сөт продукциясен, сырларны һәм сыер маен җитештерү предприятиеләрен, эремчек суын эшкәртү һәм киптерү цехларын һәм участокларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, катнаш азык предприятиеләрен һәм цехларын төзү һәм реконструкцияләүгә, нәсел продукциясен сатып алуга, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә терлекчелекне үстерү максатларында;

ит өчен терлек үрчетү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмалары тарафыннан 15 елга кадәр срокка;

ит токымнары мөгезле эре терлегенең нәсел продукциясен (материалын) сатып алуга, терлекчелек комплексларын (фермаларын), объектларын, ит саклау урыннарын, авыл хуҗалыгы терлеген һәм сотне кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү пунктларын, моңа ит һәм сөт продукциясен суыту да керә, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә терлекчелекне үстерү максатларында.

4. 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча кредитлардан (заемнардан) файдалану срокларын озайту турында килешү имзаланган очракта:

әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы "а" пунктчасының дүртенче абзацында каралган 2004 елның 1 гыйнварыннан төзелгән кредитлар (заемнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын 3 елдан артмаган вакытка озайтып башкарыла;

авыл хуҗалыгы продукциясенә 2010 елгы корылык зыян китергән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы "а" пунктчасының дүртенче абзацында каралган һәм 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын 3 елдан артмаган вакытка озайтып башкарыла;

в) әлеге Тәртипнең "а" һәм "б" пунктчаларында каралган кредитларны (заемнарны) рефинанслау өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча, тик кредитлардан (заемнардан) файдалануның гомуми суммасы әлеге пунктчаларда күрсәтелгән сроклардан артып китмәсә.

5. Әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә шартнамәне озайтуның чик срогын билгеләгәндә әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән сроклар чигендә башкарылган озайту исәпкә алынмый.

6. Заем алучыларга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр аларның төп бурычны түләп бетерү һәм исәпләнгән процентларны түләү һәм кредитны (заемны) максатчан билгеләнешендә файдалану йөкләмәләре үтәлгән очракта бирелә.

Төп бурычны түләп бетерү һәм исәпләнгән процентларны түләү йөкләмәләре бозылу аркасында исәпләнгән һәм түләнгән процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирелми.

7. Заем алучыларга процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау түбәндәгеләр буенча башкарыла:

а) әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы "а" пунктчасында каралган инвестиция кредитлары (заемнары) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) 80 проценты чигендә, ә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр һәм оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмалары тарафыннан ит токымнары мөгезле эре терлегенең нәсел продукциясен (материалын) сатып алуга, терлекчелек комплексларын (фермаларын), объектларын, мөгезле эре терлек өчен азык җитештерү объектларын, мөгезле эре терлекне чалу һәм беренчел эшкәртү өчен махсус урыннар һәм авыл хуҗалыгы терлеген һәм сөтне кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү пунктларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә алынган күрсәтелгән кредитлар (заемнар) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) 100 проценты чигендә;

әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы "б" пунктчасында каралган инвестиция

кредитлары (заемнары) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) өчтән ике өлеше күләмендә, сөт җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш) алган күрсәтелгән кредитлар (заемнар) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) 80 процентлы күләмендә, ә мөгезле эре терлек итен җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш) алган күрсәтелгән кредитлар (заемнар) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) 100 проценты күләмендә;

8. Әгәр заем алучы кредитны (заемны) чит ил валютасында алган булса, чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр кредит буенча процентлар түләү көненә чит ил валютасына карата сумның Россия Федерациясе Үзәк банкы билгеләгән курсыннан чыгып бирелә. Чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр исәпләгәндә, чит ил валютасында алынган кредитның (заемның) чик процент ставкасы еллык 10,5 процент күләмендә билгеләнә.

9. Заем алучыларга чыгымнарының бер өлешен каплауга бирелә торган субсидияләр кредитлар (заемнар) буенча процентлар түләүгә заем алучыларның факттагы чыгымнарыннан артык булырга тиеш түгел.

10. Субсидияләрнең күләмен исәпләү Россия Федерациясе Үзәк банкының кредит шартнамәсен (заем шартнамәсен) төзегән көнгә, ә кредит шартнамәсенә (заем шартнамәсенә) кредиттан (заемнан) файдаланган өчен түләү арту белән бәйле өстәмә килешү төзелгән очракта – кредит шартнамәсенә (заем шартнамәсенә) өстәмә килешү төзегән көнгә гамәлдә булган рефинанслау ставкасы буенча башкарыла.

11. Субсидияләр алу өчен заем алучылар Татарстан Республикасы муниципаль районнарында ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

әлеге боерыкка 40 нчы кушымтада каралган форма буенча түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

кредит шартнамәсенең (заем шартнамәсенең) кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен, кредит (заем) алу турында ссуда счетыннан өземтәне, түләп бетерү һәм аның буенча процентлар түләү графигын;

әлеге боерыкка 13 нче кушымтада каралган исемлек буенча кредитның (заемның) максатчан билгеләнешендә кулланылуын раслый торган документларның заем алучы тарафыннан таныкланган күчермәләрен – кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап;

әлеге боерыкка 41 нче кушымтада каралган форма буенча кредитны (заемны) түләп бетерү һәм аның буенча процентлар түләү графигын;

әлеге боерыкка 42 нче кушымтада каралган форма буенча агымдагы финанс

елына субсидияләр күләменең планлаштырылган исәп-хисабын;

әлеге боерыкка 36 нчы кушымтада каралган форма буенча субсидияләр күләменең исәп-хисабын (субсидияләр элек финансланган чорлары өчен яңадан исәпләнми торган бирелгән исәп-хисаплар буенча түләнә);

әлеге боерыкка 43 нче кушымтада каралган форма буенча кредит акчаларын үзләштерү турында белешмәне.

12. Заемга алучы үз теләге белән салым һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча срогы чыккан бурычлары булмау турында салым органы белешмәсен тапшырырга хокуклы.

Әгәр заем алучы күрсәтелгән документны үз теләге белән тапшырмаса, Министрлык аны ведомствоара сорату юлы белән Федераль салым хезмәтеннән соратып ала.

13. Кредитның (заемның) максатчан билгеләнешендә кулланылуын раслый торган документларның заем алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре, кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап:

Россия дәүләт стандарты оешмасының 1993 елның 30 декабрендәге 301 номерлы карары белән расланган ОК005-93 Бөтенроссия продукция классификаторы нигезендә (аңа кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып) билгеләнгән авыл хуҗалыгы техникасын, җиһазларын, махсуслаштырылган транспортны һәм махсус техниканы сатып алу өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча;

авыл хуҗалыгы техникасы, махсуслаштырылган транспорт һәм махсус техника һәм җиһазлар өчен түләүне, аванс түләүләрен дә кертеп, раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

җиһаз өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм/яки документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

авыл хуҗалыгы техникасын, махсуслаштырылган транспортны һәм махсус техниканы һәм җиһазларны сатып алу (лизингка) шартнамәләренең күчермәләре;

авыл хуҗалыгы техникасын, махсуслаштырылган транспортны һәм махсус техниканы һәм җиһазларны сатып алуга товар-транспорт накладнойларының, счет-фактураларының күчермәләре;

авыл хуҗалыгы техникасын, махсуслаштырылган транспортны һәм махсус техниканы һәм җиһазларны кабул итү – тапшыру актларының күчермәләре ( № ОС-1, № ОС-1б, № ОС-15 формалары)*;

юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе органнарында һәм дәүләт техника күзәтчелеге органнарынада теркәлү турында тамга сугылган транспорт чаралары паспортының, үзйөрешле машиналар паспортының күчермәләре.

Россия Федерациясе территориясендә җитештерелми торган җиһазларны чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:

чит ил җиһазын сатып алу контрактының күчермәсе;

валютаны күчерүне раслау турында свифт хәбәрләренең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен контракт нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә рәмиләштергәннән соң

тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-бирешенең паспортының торышы турында белешмә;

җиһазларны кабул итү – тапшыру актларының күчермәләре ( № ОС-1, № ОС-1б, № ОС-15 формалары)*;

Нәселле продукцияне сатып алу очен алынган кредитлар (заемнар) буенча:

нәселле продукция (материал) очен түләүне, аванс түләүләрен дә кертеп,раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

нәселле продукцияне сатып алу (лизингка) шартнамәләренең күчермәләре;

нәселле продукцияне кабул итү – тапшыру актларының күчермәләре;

нәселле продукцияне сатып алу счет-фактураларының күчермәләре һәм нәсел таныклыклары реестры.

Нәселле продукцияне (материалны) чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:**:

нәселле продукция (материал) өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм/яки документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

нәселле продукцияне (материалны) сатып алу контрактының күчермәсе;

валютаны күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен контракт нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-бирешенең паспортының торышы турында белешмә.

Төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектны төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә һәм (яки) модернизацияләүгә җыелма сметаның күчермәсе.

Эшләрне подряд алымы белән башкарганда:

технологик җиһазлар, башка эшләр өчен (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) түләүне һәм эшләр башкару өчен подрядчыларга акча күчерүне, шул исәптән аванс түләүләре буенча) раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

технологик җиһазлар китерүгә, подряд эшләре, башка эшләр (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) башкаруга шартнамәләрнең, төзелеш-монтаж эшләренең чыгымнары сметасы һәм башкару графигының заемга алучы һәм подрядчы тарафыннан расланган күчермәләре;

төзелеш материаллары, юридик һәм физик затларның эшләре һәм хезмәт күрсәтүләре өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

технологик җиһаз алуга товар-транспорт накладнойларының, счет-фактураларның күчермәләре;

җиһазны монтажга кабул итү – тапшыру актларының күчермәләре (№ ОС-1, формасы)*.

Заем алучы төзелеш материаллары өчен түләгәндә:

төзелеш материалларын китерү шартнамәләренең күчермәләре;

заем алучының төзелеш материалларын алуына товар-транспорт накладнойларының күчермәләре;

төзелеш материалларын аларның бәяләрен № КС-3* формасына кертү өчен подрядчыга тапшыру документларының күчермәләре;

башкарылган эшләрне кабул итү турында актларның заем алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре (№ КС-2 формасы)*;

башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында белешмәнең заемга алучы һәм подрядчы тарафыннан расланган күчермәсе (№ КС-3 формасы)*.

Эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда:

төзелеш материаллары, юридик һәм физик затларның эшләре, хезмәт күрсәтүләре өчен өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

эшләрне хуҗалык ысулы белән башкару өчен җаваплы затларны һәм аның графигын билгеләү һәм эш күләме (мең сумнарда) турында боерыкның күчермәсе;

җыелма смета исәп-хисапларының һәм локаль сметаларның күчермәсе, эшләрне хуҗалык ысулы белән башкару турында боерык, башкарылган эшләр актларының күчермәләре (№ КС-2 формасы)*;

башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында белешмәләр (№ КС-3 формасы)*;

технологик җиһазлар китерүгә, аерым эшләрне (проект эшләрен, экспертизаны, техник күзәтчелекне) подряд ысулы белән башкаруга шартнамәләрнең күчермәләре;

технологик җиһазлар өчен түләүне һәм подрядчыларга акча күчерүне, шул исәптән аванс түләүләре буенча, раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

Җиһазларны чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар**:

импорт җиһазны сатып алу контрактының күчермәсе;

җиһаз өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм/яки документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

товар китерүчегә валютаны күчерүне раслау турында дебет авизосының яки валютаны күчерү белән свифт хәбәренең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен контракт нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-бирешенең паспортының торышы турында белешмә;

җиһазны монтажга кабул итү – тапшыру актларының күчермәләре (№ ОС-15 формасы)*.

Крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары өчен:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектларны төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә һәм (яки) модернизацияләүгә җыелма сметаның күчермәсе;

технологик җиһазлар китерүгә, подряд эшләрен, башка эшләрне (проект эшләрен, экспертизаны, техник күзәтчелекне) башкаруга шартнамәләрнең, төзелеш-монтаж эшләре башкару чыгымнары сметасының һәм аларны башкару графигының күчермәләре.

Эшләр графигы үтәлеп барганда заем алучы тапшыра торган документлар:

подряд ысулы белән башкарыла торган эшләр, башка эшләр (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) һәм технологик җиһаз өчен, аванс түләүләрен дә кертеп, төзелеш материаллары һәм эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда читтәге оешмаларның хезмәт күрсәтүләре өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

башкарылган эшләр актларның күчермәләре;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итеп алу – тапшыру актларының күчермәләре (төзелеш тәмамланганнан соң тапшырыла, бу вакытта заем алучыларга субсидия эш этапларын үтәүгә карап түләнә).

Җиһазларны чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар**:

импорт җиһазны сатып алу контрактының күчермәсе;

җиһаз өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм/яки документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валютаны күчерү белән свифт хәбәренең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен контракт нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-бирешенең паспортының торышы турында белешмә;

бинаны (корылманы) кабул итү – тапшыру турында (№ ОС-1а формасы)* актларның һәм (яки) төп чараларның реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларын кабул итү – тапшыру турында (№ ОС-3 формасы)* актларының күчермәләре (төзелеш тәмамланганнан соң тапшырыла, бу вакытта заем алучыларга субсидия эш этапларын үтәүгә карап түләнә).

Күпьеллык үсемлекләрне утыртканда:

утырту материаллары һәм (яки) шпалер кую өчен материаллар өчен, аванс түләүләрен дә кертеп, түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

төп чараларны кабул итү – тапшыру турында (№ ОС-1 формасы)* актларының күчермәләре.

Утырту материалларын чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар**:

импорт җиһазны сатып алу контрактының күчермәсе;

утырту материалын сатып алу кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

түләү йөкләмәләренең һәм (яки) утырту материалына түләү өчен аккредитив ачуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валютаны күчерү белән свифт хәбәренең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен контракт нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-бирешенең паспортының торышы турында белешмә;

төп чараларны кабул итү – тапшыру турында (№ ОС-1 формасы)* актларының күчермәләре.

Искәрмә:

* № ОС-1а, № ОС-15, № КС-2, № КС-3, № ОС-1 формалары буенча субсидияне исәпләгәндә (максатчан кулланылышын раслау) суммалар максатчан кулланылуга НДС ны исәпкә алып кабул ителә.

**кредитны чит ил валютасында алган һәм анны сумнарда файдаланган очракта, инвестиция кредитының максатчан кулланылышын раслый торган документлар исемлеге сумнарда алынган инвестиция кредитының максатчан кулланылышын раслау өчен билгеләнгән документларның исемлегенә туры килә.

Документлар агымдагы айның 1 сеннән 10 нчы числосына кадәр тапшырыла.

14. Идарә заем алучылар тапшырган документларны тикшерә, субсидияләрнең күләмен исәпләүләрне дүрт көн эчендә килештерә һәм аларны заем алучыга кире кайтара.

15. Заем алучы әлеге Тәртипнең 11-13 пунктларында күрсәтелгән Идарә тарафыннан килештерелгән документларны Министрлыкка агымдагы айның 1 сеннән 20 нче числосына кадәр тапшыра.

Министрлык заем алучы тапшырган документларны тикшерә, заем алучының гаризасын журналга терки, ул номерлана, шнурлана һәм аңа Министрлык мөһере сугыла һәм кабул ителгән документларны теркәгән көнән соң 6 көн эчендә аларны карауга кабул итү турында яки аны кабул итүдән баш тарту турында моның сәбәбен күрсәтеп язмача хәбәр итә.

Заем алучы тарафыннан субсидия алу өчен тапшырылган документлар Министрлык тарафыннан алты эш көне эчендә карала.

Заем алучыга субсидия бирүдә баш тартылса, Министрлык теркәү журналына тиешле язма кертә, заем алучыга исә алты көн эчендә тиешле язма хәбәрнамә юллана.

16. Документларны карауга алуда түбәндәге очракларда баш тартыла:

тиешле финанс елына Министрлыкка бу максатларга каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары булмаганда;

заем алучы тарафыннан Министрлыкка документларның тулы пакеты тапшырылмаганда яки вакытында тапшырылмаганда.

Субсидияләр бирүдә түбәндәге очракларда баш тартыла:

тапшырылган документлар субсидияләр бирү шартларына туры килмәгәндә;

тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр булганда.

17. Субсидияләрне күчерү Министрлыкның Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан заем алучыларның исәп-хисап счетларына әлеге боерыкка 36 нчы кушымтада каралган форма буенча субсидияләр күләме исәп-хисабына нигезләнеп башкарыла.

18. Алынган субсидияләр субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

19. Кредитларның һәм заемнарның максатчан кулланылышын раслый торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык заем алучыга йөкләнә.

20. Кредитларның максатчан кулланылышы буенча тапшырыла торган документларның дөреслеген тикшереп тору Идарәләрнең башлыкларына йөкләнә.

21. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

2014 елның 24 февралендәге
33/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
9 нчы кушымта

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына 8 елга кадәр срокка алынган кредитлары һәм заемнары буенча проңентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен 2014 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип 8 елга кадәрге срокка россия кредит оешмаларында алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларында алынган заемнар буенча проңентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау максатларында 2014 елда Россия Федерацияcе бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирүне регламентлаштыра.

2. Субсидияләр авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына (алга таба – заем алучылар) бирелә.

3. Субсидияләр түбәндәгеләр тарафыннан алынган кредитлар (заемнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга бирелә:

а) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга түбәндәге чорларда төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2005 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 5 елга кадәр срокка – кечкенә габаритлы авыл хуҗалыгы техникасын, егәрлеге 100 ат көченә кадәр булган тракторларны һәм алар белән бергә агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналарын, тулы массасы 3,5 тоннадан артмаган йөк ташучы автомобильләрне сатып алуга;

2005 елның 1 гыйнварыннан алып 5 елга кадәр срокка – шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 700 мең сумнан артып китмәгәндә, авыл хуҗалыгы терлеген, терлекчелек һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү җиһазларын сатып алуга, шулай ук терлекчелек биналарын ремонтлауга, реконструкцияләүгә һәм төзүгә, газ җиһазларын сатып алуга һәм газ челтәрләренә тоташуга;

2007 елның 1 гыйнварыннан алып 2 елга кадәр срокка – шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 300 мең сумнан артып китмәгәндә, ягулык материаллары, авыл хуҗалыгы техникасын һәм терлекчелек биналарын ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар, минераль ашламалар, үсемлекләрне яклау чараларын, азыкларны, ветеринария препаратларын һәм

сезонлы эшләр башкару өчен башка матди ресурсларны, шул исәптән теплицалар өчен материалларны, яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә;

2008 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 5 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл җирендә туристлыкны үстерү (авыл туризмы), халык кәсепләрен, авыл җирендә сәүдәне үстерүне дә кертеп, шулай ук халыкка көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтү, кыргый җиләк-җимешләрне, дару үләннәрен һәм башка ашый торган һәм агач булмаган урман ресурсларын хәзерләү һәм эшкәртү белән бәйле юнәлешләрне үстерүгә;

2008 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 5 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә яңгыр яудыру һәм су сибү, насос станцияләре машиналарын, җайланмаларын һәм аппаратларын сатып алуга;

б) крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан түбәндәге чорларда төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2005 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка –авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын, шул исәптән терлекчелек, кошчылык, азык җитештерү өчен файдаланыла торган тракторларны һәм алар белән бергә агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналарын, җиһазларын, яңгыр яудыру һәм су сибү, насос станцияләре машиналарын, җайланмаларын һәм аппаратларын, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ ягулыгына күчерү өчен җиһазлар сатып алуга;

2005 елның 1 гыйнварыннан алып 8 елга кадәр срокка – агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 10 миллион сумнан артып китмәгәндә, авыл хуҗалыгы продукциясен саклауга һәм эшкәртүгә, нәселле авыл хуҗалыгы терлеген, нәселлек продукциясен (материалын), бәрәңге базларын, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, ябык грунтта җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен җитештерү буенча теплаца комплексларын, җитенне һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, авыл хуҗалыгы үсемлекләренең орлыкларын хәзерләү комплексларын, терлекчелек комплексларын (фермаларын), терлекчелек, азык җитештерү объектларын күпьеллык үсемлекләр өчен ялгау комплекларын төзүгә, реконструкцияләүгә, күпьеллык үсемлекләр һәм виноградлыклар утыртуга

2007 елның 1 гыйнварыннан алып 2 елга кадәр срокка – агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 5 миллион сумнан артып китмәгәндә, ягулык материаллары, авыл хуҗалыгы техникасын һәм терлекчелек биналарын ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар, минераль ашламалар, үсемлекләрне яклау чараларын, азыкларны, ветеринария препаратларын һәм сезонлы эшләр башкару өчен башка матди ресурсларны, шул исәптән теплицалар өчен материалларны, яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып

алуга, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә;

2008 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 5 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннанраслана торган исемлек нигезендә авыл җирендә туристлыкны үстерү (авыл туризмы), халык кәсепләрен, авыл җирендә сәүдәне үстерүне дә кертеп, шулай ук халыкка көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтү, кыргый җиләк-җимешләрне, дару үләннәрен һәм башка ашый торган һәм агач булмаган урман ресурсларын хәзерләү һәм эшкәртү белән бәйле юнәлешләрне үстерүгә;

в) авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары тарафыннан түбәндәге чорларда төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2005 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка –авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын (Россиядә һәм чит илдә җитештерелгән), шул исәптән катнаш азыкны, инкубация йомыркаларын, нәселле яшь терлекне һәм кош-кортларны ташу өчен махсуслаштырылган транспортка, терлекчелек, кошчылык, азык җитештерү өчен файдаланыла торган тракторларны һәм алар белән бергә агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналарын, җиһазларын, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ ягулыгына күчерү өчен җиһазлар сатып алуга;

2005 елның 1 гыйнварыннан алып 8 елга кадәр срокка – агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер кооперативка 40 миллион сумнан артып китмәгәндә, махсуслаштырылган технологик җиһазлар, суыткычлар, авыл хуҗалыгы терлеген, нәселлек продукциясен (материалын) сатып алуга, бәрәңге базларын, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, ябык грунтта җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен җитештерү буенча теплица комплексларын, җитенне һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, авыл хуҗалыгы базарларын, сату мәйданнарын, сөт, ит, яшелчә, җиләк-җимеш һәм башка авыл хуҗалыгы продукциясен кабул итү, беренчел эшкәртү һәм саклау пунктларын төзүгә, реконструкцияләүгә, шулай ук күпьеллык үсемлекләр һәм виноградлыклар утыртуга, күпьеллык үсемлекләр өчен ялгау комплекларын төзүне һәм реконструкцияләүне дә кертеп,

2007 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 2 елга кадәр срокка – авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар сатып алуга, шул исәптән аларны кооператив әгъзаларына китерүгә;

2007 елның 1 гыйнварыннан алып 2 елга кадәр срокка – агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер кооперативка 15 миллион сумнан артып китмәгәндә, сезонлы эшләр башкару өчен башка матди ресурсларны, яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга, беренчел һәм сәнәгать эшкәртүе өчен үзебездәге авыл хуҗалыгы чималын (2013 елдан башлап - беренчел һәм сәнәгать эшкәртүе өчен үзебездәге авыл хуҗалыгы чималын), кооператив әгъзалары тарафыннан алга таба сату өчен җитештерелгән авыл

хуҗалыгы продукциясен сатып алуга, шулай ук кооперативны оештырылу ягыннан тозекләндерүгә һәм авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә;

2008 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 5 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл җирендә туристлыкны үстерү (авыл туризмы), халык кәсепләрен, авыл җирендә сәүдәне үстерүне дә кертеп, шулай ук халыкка көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтү, кыргый җиләк-җимешләрне, дару үләннәрен һәм башка ашый торган һәм агач булмаган урман ресурсларын хәзерләү һәм эшкәртү белән бәйле юнәлешләрне үстерүгә.

4. 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча кредитлардан (заемнардан) файдалану срокларын озайту турында килешү имзаланган очракта:

әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы "а" пунктчасының икенче һәм өченче абзацларында каралган 2005 елның 1 гыйнварыннан төзелгән кредитлар (заемнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын 2 елдан артмаган вакытка озайтып башкарыла;

әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы "а" пунктчасының дүртенче абзацында каралган кредитлар (заемнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын 1 елдан артмаган вакытка озайтып башкарыла;

авыл хуҗалыгы продукцияләренә 2010 елгы корылык зыян китергән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан әлеге Тәртипнең 3 пунктчасында каралган һәм 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын 3 елдан артмаган вакытка озайтып башкарыла;

5. Заем алучыларга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр аларның төп бурычны түләп бетерү һәм исәпләнгән процентларны түләү һәм кредитны (заемны) максатчан билгеләнешендә файдалану йөкләмәләре үтәлгән очракта бирелә. Төп бурычны түләп бетерү һәм исәпләнгән процентларны түләү йөкләмәләре бозылу аркасында исәпләнгән һәм түләнгән процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирелми.

6. Заем алучыларга процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган кредитлар (заемнар) буенча башкарыла:

2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) - кредит шартнамәсен (заем шартнамәсен) төзегән көндә гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) 95 проценты күләмендә,

2013 елның 1 гыйнварыннан башлап төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) - Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) өчтән ике өлеше нты күләмендә.

7. Заем алучыларга чыгымнарының бер өлешен каплауга бирелә торган субсидияләр кредитлар (заемнар) буенча процентлар түләүгә заем алучыларның факттагы чыгымнарыннан артык булырга тиеш түгел.

8. Татарстан Республикасы муниципаль районнарында ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) заем алучылардан түбәндәге документларны кабул итеп ала:

а) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар алган кредитлар (заемнар) буенча:

әлеге боерыкка 44 нче кушымтада каралган форма буенча субсидияләр бирү турында гаризаны;

кредит шартнамәсенең (заем шартнамәсенең) кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен, кредит (заем) алу турында ссуда счетыннан өземтәне, түләп бетерү һәм аның буенча процентлар түләү гарфигын;

әлеге боерыкка 37, 38 нче кушымталарда каралган формалар буенча субсидияләр күләменең исәп-хисабын;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның шәхси ярдәмче хуҗалыгын теркәү турында хуҗалык кенәгәсеннән өземтәне;

кредитның (заемның) максатчан билгеләнешендә кулланылуын раслый торган документларның башкарма комитет тарафыннан таныкланган күчермәләрен – түбәндәгеләр өчен алынган кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап:

кечкенә габаритлы авыл хуҗалыгы техникасын, егәрлеге 100 ат көченә кадәр булган тракторларны һәм алар белән бергә агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналарын, тулы массасы 3,5 тоннадан артмаган йөк ташучы автомобильләрне сатып алуга:

кечкенә габаритлы авыл хуҗалыгы техникасын, йөк ташучы автомобильләрне, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын һәм җиһазларын оешмаларда, ваклап сату җирләрендә яки индивидуаль эшкуарлардан сатып алганда тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән сату-алу шартнамәләренең яки накладнойларының яки товар чекларының, шулай ук түләү йөкләмәләренең яки касса чекларының яки приход касса ордерларының төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

кечкенә габаритлы авыл хуҗалыгы техникасын, йөк ташучы автомобильләрне, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын һәм җиһазларын физик затлардан акчалата исәп-хисап белән сатып алганда заем алучыдан акчалар алу күрсәтелгән сату-алу шартнамәләренең һәм сатучылар (товар китерүчеләр) биргән распискаларның төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

транспорт чараларын сатып алганда билгеләнгән тәртиптә исәпкә куелу турында тамга булган транспорт чаралары паспортларының төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

муниципаль берәмлекнең – шәһәр һәм авыл җирлекләренең – башкарма комитетыннан (алга таба – башкарма комитет) хуҗалык кенәгәләреннән белешмә-өземтәләр;

муниципаль районда шәхси ярдәмче хуҗалык тарафыннан алынган кредитның максатчан үзләштерелүен тикшерү турында әлеге боерыкка 45 нче кушымтада каралган форма буенча башкарма комитет тарафыннан рәсмиләштерелгән актны.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 700 мең сумнан артып китмәгәндә, авыл хуҗалыгы терлеген, терлекчелек һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү җиһазларын сатып алуга, шулай ук терлекчелек биналарын ремонтлауга, реконструкцияләүгә һәм төзүгә, газ җиһазларын сатып алуга һәм газ челтәрләренә тоташуга:

авыл хуҗалыгы терлеген сатып алганда тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән сату-алу шартнамәләренең яки накладнойларының яки товар чекларының, шулай ук түләү йөкләмәләренең яки касса чекларының яки приход касса ордерларының төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

авыл хуҗалыгы терлеген физик затлардан акчалата исәп-хисап белән сатып алганда заем алучыдан акчалар алу күрсәтелгән сату-алу шартнамәләренең һәм сатучылар (товар китерүчеләр) биргән расписокаларның төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

сатып алганда авыл хуҗалыгы терлегенең хәрәкәте турында башкарма комитетыннан (алга таба – башкарма комитет) хуҗалык кенәгәләреннән белешмә-өземтәләр;

төзелә яки реконструкцияләнә торган терлекчелек биналарының, аларның зурлыклары һәм кулланыла торган материалларны күрсәтеп, заем алучы тарафыннан имзаланган схемасын;

заем алучы тарафыннан төзелгән һәм имзаланган, башкарма комитет тарафыннан расланган чыгымнар сметаларын, чыгымнар сметасына ярашлы рәвештә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән касса чекларының яки приход касса ордерларының, сатып алынган материалларга товар накладнойларының яки товар чекларының төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

терлекчелек биналарын реконструкцияләү, модернизацияләү һәм төзү эшләрен башкаруга (подряд ысулы белән) шартнамәләрнең, терлекчелек биналарын реконструкцияләгәндә, модернизацияләгәндә һәм төзегәндә башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган башкарылган эшләр актларының һәм түләү документларының төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

җиһазларны алу накладнойларының (товар чекларының) һәм газ җиһазларын, материаллары өчен түләүне раслый торган түләү документларының төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

газ челтәрләренә тоташканда башкарылган эшләр актларының һәм башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү документларының төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

муниципаль районда шәхси ярдәмче хуҗалык тарафыннан алынган кредитның максатчан үзләштерелүен тикшерү турында әлеге боерыкка 45 нче кушымтада каралган форма буенча башкарма комитет тарафыннан рәсмиләштерелгән актны.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 300 мең сумнан артып китмәгәндә, ягулык материаллары, авыл хуҗалыгы техникасын һәм терлекчелек биналарын ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар, минераль ашламалар, үсемлекләрне яклау чараларын, азыкларны, ветеринария препаратларын һәм сезонлы эшләр башкару өчен башка матди ресурсларны, шул исәптән теплицалар өчен материалларны, яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә:

матди ресурсларны юридик затлардан яки индивидуаль эшкуарлардан сатып алганда, тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән сату-алу шартнамәләренең яки накладнойларының яки товар чекларының, шулай ук түләү йөкләмәләренең яки касса чекларының яки приход касса ордерларының төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

авыл хуҗалыгы яшь терлеген һәм азыкны физик затлардан сатып алганда акчалата исәп-хисап белән сатып алганда заем алучыдан акчалар алу күрсәтелгән сату-алу шартнамәләренең һәм сатучылар (товар китерүчеләр) биргән распискаларның төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

иминләштерү шартнамәләренең һәм иминият кертемнәрен түләүгә түләү документларының төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

матди товар кыйммәтләр һәм төп чаралар заем алучы белән бергә яшәми торган һәм (яки) аның белән бергә шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып бармый торган физик затлардан сатып алынырга тиеш. Әгәр заем алучы шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып баручы граждан яки заем алучы белән бергә яшәүче һәм (яки) аның белән бергә шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып баручы физик зат булса, бер үк ук вакытта индивидуаль эшкуарлар булып торсалар, матди товар кыйммәтләр һәм төп чараларны сатып алу башка индивидуаль эшкуарлар белән башкарылырга тиеш;

башкарма комитеттан хуҗалык кенәгәләреннән белешмә-өземтәләрне;

муниципаль районда шәхси ярдәмче хуҗалык тарафыннан алынган кредитның максатчан үзләштерелүен тикшерү турында әлеге боерыкка 45 нче кушымтада каралган форма буенча башкарма комитет тарафыннан рәсмиләштерелгән актны.

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл җирендә туристлыкны үстерү (авыл туризмы), халык кәсепләрен, авыл җирендә сәүдәне үстерүне дә кертеп, шулай ук халыкка көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтү, кыргый җиләк-җимешләрне, дару үләннәрен һәм башка ашый торган һәм агач булмаган урман ресурсларын хәзерләү һәм эшкәртү белән бәйле юнәлешләрне үстерүгә:

заем алучы тарафыннан төзелгән һәм имзаланган, башкарма комитет тарафыннан расланган чыгымнар сметаларын;

чыгымнар сметасына ярашлы рәвештә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән касса чекларының яки приход касса ордерларының, сатып алынган материалларга товар накладнойларының яки товар чекларының төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

объектларны реконструкцияләү, модернизацияләү һәм төзү эшләрен башкаруга (подряд ысулы белән) шартнамәләрнең, объектларны реконструкцияләгәндә, модернизацияләгәндә һәм төзегәндә башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган башкарылган эшләр актларының һәм түләү документларының төп нөсхәләрен, күчермәләрен;

башкарма комитеттан хуҗалык кенәгәләреннән белешмә-өземтәләрне;

муниципаль районда шәхси ярдәмче хуҗалык тарафыннан алынган кредитның максатчан үзләштерелүен тикшерү турында әлеге боерыкка 45 нче кушымтада каралган форма буенча башкарма комитет тарафыннан рәсмиләштерелгән актны.

б) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар алган кредитлар (заемнар) буенча:

әлеге боерыкка 44 нче кушымтада каралган форма буенча субсидияләр бирү турында гаризаны;

кредит шартнамәсенең (заем шартнамәсенең) кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен, кредит (заем) алу турында ссуда счетыннан өземтәне, түләп бетерү һәм аның буенча процентлар түләү гарфигын;

әлеге боерыкка 37, 38 нче кушымталарда каралган формалар буенча субсидияләр күләменең исәп-хисабын;

кредитның (заемның) максатчан билгеләнешендә кулланылуын раслый торган документларның заем алучы тарафыннан таныкланган күчермәләрен – түбәндәгеләр өчен алынган кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап:

авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын, шул исәптән терлекчелек, кошчылык, азык җитештерү өчен файдаланыла торган тракторларны һәм алар белән бергә агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналарын, җиһазларын, яңгыр яудыру һәм су сибү, насос станцияләре машиналарын, җайланмаларын һәм аппаратларын, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ ягулыгына күчерү өчен җиһазлар сатып алуга:

авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын сатып алу (лизингка) шартнамәләренең күчермәләрен;

авыл хуҗалыгы техникасы һәм җиһазлар өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын сатып алуга товар-транспорт накладнойларының, счет-фактураларының күчермәләрен;

транспорт чараларын сатып алганда тиешле тәртиптә исәпкә куелу турында тамга сугылган транспорт чаралары паспортларының күчермәләрен.

Авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:

импорт авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазын сатып алу контрактының күчермәсе;

авыл хуҗалыгы техникасы һәм җиһазы өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм/яки документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валютаны күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен контракт нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-бирешенең паспортының торышы турында белешмә;

транспорт чараларын сатып алганда тиешле тәртиптә исәпкә куелу турында тамга сугылган транспорт чаралары паспортларының күчермәләрен.

Агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 10 миллион сумнан артып китмәгәндә, авыл хуҗалыгы продукциясен саклауга һәм эшкәртүгә, нәселле авыл хуҗалыгы терлеген, нәселлек продукциясен (материалын), бәрәңге базларын, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, ябык грунтта җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен җитештерү буенча теплица комплексларын, җитенне һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, авыл хуҗалыгы үсемлекләренең орлыкларын хәзерләү комплексларын, терлекчелек комплексларын (фермаларын), терлекчелек, азык җитештерү объектларын күпьеллык үсемлекләр өчен ялгау комплекларын төзүгә, реконструкцияләүгә, күпьеллык үсемлекләр һәм виноградлыклар утыртуга:

нәселле авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) сатып алу (лизингка) шартнамәләренең күчермәләрен;

нәселле авыл хуҗалыгы терлеге, нәселле продукция (материал) өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

нәселле авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) кабул итү – тапшыру актларының күчермәләрен;

нәселле авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) сатып алуга нәсел таныклыкларының күчермәләрен.

Нәселле продукцияне (материалны) чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:

нәселле авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) сатып алу (лизингка) шартнамәләренең күчермәләрен;

нәселле авыл хуҗалыгы терлеге, нәселле продукция (материал) өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

валютаны күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләрен;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсен (йөк таможнясы декларациясен контракт нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсен;

импорт алыш-бирешенең паспортының торышы турында белешмәне;

нәселле авыл хуҗалыгы терлегенең, нәселле продукциянең (материалның) нәселлек ягыннан кыйммәтен раслый торган документларның күчермәләрен;

Төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектны төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә һәм (яки) модернизацияләүгә җыелма сметаның күчермәсе.

Эшләрне подряд алымы белән башкарганда:

технологик җиһазлар, башка эшләр өчен (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) түләүне һәм эшләр башкару өчен подрядчыларга акча күчерүне, шул исәптән аванс түләүләре буенча) раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

башкарылган эшләр актларының күчермәләрен;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итү – тапшыру актларының күчермәләрен (төзелеш беткәннән соң тапшырыла, бу вакытта субсидия эшләрнең башкарылуына карап бирелә).

Күпьеллык үсемлекләрне һәм виноградлыкларны утырканда:

Утырту материаллары һәм шпалерлар кую өчен каралган материаллар өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләрен;

утыртуны кабул итү актларының күчермәләрен (эшләр төгәлләнгәннән соң)

Утырту материалын чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:

утырту материалын сатып алу шартнамәләренең күчермәләрен;

утырту материалы өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

валютаны күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләрен;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсен (йөк таможнясы декларациясен контракт нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсен;

